**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 21.09.2023** **№ 1349**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Гаиләдә белем алу һәм үзлегеңнән белем алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 04 сентябрендәге 1486 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гомуми белем алу формасын сайлауга Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын тәэмин итү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Гаиләдә белем алу һәм үзлегеңнән белем алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 04 сентябрендәге 1486 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 һәм 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Укучы гаиләдә белем алу/үзлегеңнән белем алу формасында белем алганда, яшәү территориясе беркетелгән гомуми белем бирү оешмасында арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узарга мөмкин».

«3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә экстерннар йомгаклау аттестациясен уздыруда катнашкан педагог хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүне оештырырга».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - мәгариф бүлеге башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин